

**“Тукай кайта язлар белән”**

Бөек шагыйрь Г. Тукайның туган көнен билгеләп үтү Бәзәкә китапханәсендә матур традициягә әйләнде. Быел ул башлангыч класс укучылары өчен әзерләнгән иде һәм “Тукай кайта язлар белән” дип аталды. Әдәби кичәдә Г.Тукайның биографиясен кыскача искә төшереп киткәннән соң укучылар “Г.Тукайның иҗатын беләсеңме?” дигән мини-викторина сорауларына җавап бирделәр, аннары китапханәче Ф.Башарова балаларны

“Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын;

Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын.” дип аталган китап киштәсендәге китаплар белән таныштырды һәм укырга тәкъдим итте. Кичәнең соңгы өлеше Г.Тукайның мәсәлләрен укуга багышланды. Шагыйрь мәсәлләрендә икейөзле, надан, ялкау, мактанчык кешеләрне сүрәтли, шуның белән укучыга тырыш, сабыр, эшчән булырга,олыларны хөрмәт итәргә үгет-нәсыйхәт бирә. Кичәдә катнашкан укучылар тагын бер кат шушы хакыйкатьне күңелләренә салып киттеләр.


Хәтер
йөрәкләрдә яшәсен!


Хәтер
йөрәкләрдә яшәсен!


Г.Тукайның
иҗаты буенча
мини-
викторина
Хәтер
йөрәкләрдә яшәсен!

